**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы**
**Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең**
**Иске Минзәләбаш авылы**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№2** **18.11.2023**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Иске Минзәләбаш авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Минзәләбаш авыл җирлегенең Иске Минзәләбаш авылы халык җыены карар итте:

1. I төркем инвалидлар; олы яшьтәге ялгыз гражданнар; вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар; контракт буенча хәрби хезмәт үтүче гражданнар; өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылганнар һәм аларның гаилә әгъзалары; уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлар; хөкем ителгәннәр; авыр тормыш хәлендә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, Иске Минзәләбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә узара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга :

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен җиһазларны тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;

2) урамнарны яктырту эшләрен оештыру;

3) су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итә торган башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, халыкка су ташу һәм су бирү системаларын проектлау;

4) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр);

5) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

6) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

7) халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның күпләп ял итү өчен башка урыннар) төзекләндерү һәм алар янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү;

8) традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, төзекләндерү.

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http:// sarmanovo. tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Иске Минзәләбаш авыл җирлеге башлыгы А.Н.Габдрахманов